Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Татар Чаллысы авыл җирлегенең Татар Чаллысы авылында гражданнар җыены

**Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Татар Чаллысы авыл җирлеге территориясендә үзара салым кертү турында**

**КАРАР**

20 ноябрь 2025 ел № 3

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлеге башлыгының "Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлегенең Татар Чаллысы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында" 2025 елның 10 ноябрендәге 6 нчы номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлегенең Татар Чаллысы авылында гражданнар җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2026 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районы Татар Чаллысы авыл җирлегенең Татар Чаллысы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидларны, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентларны түләүдән азат итәргә, ә күп балалы гаиләләргә түләүне 50%ка киметеп 500 сум күләмендә кертергә һәм үзара салым акчаларын җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә.

1) Су белән тәэмин итү, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;(суга батыру насослары сатып алу)
2) Торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (Беларус 82.1 тракторын тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү (запас частьләр, дизель ягулыгы сатып алу, тракторчыга хезмәт өчен түләү)) (бензин триммерлары, кече архитектура формалары сатып алу)
3) Каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыклары төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу.
4) Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (вак таш сатып алу)
   Узган еллардан калган үзара салым акчаларын "торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерүгә" кертергә

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм www Менделеевск муниципаль

районының рәсми сайтында http:///mendsleevsk.tatarstan.ru “Татар Чаллысы авыл җирлеге” бүлегендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Татар Чаллысы авыл җирлеге башлыгы Т.П. Кузнецова.